| | |
|---|---|
| Совет Абалачевского сельского<br>поселения Менделеевского<br>муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Абалач авыл<br>Җирлеге Советы |

| | |
|---|---|
| Решение<br>09.02.2023 ел | Карар<br>№ 90 |

"Җир салымы турында"
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге
Советының 2020 елның 27 февралендәге
131 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге советының 2020 елның 27 февралендәге 131 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәгечә бәян итәргә: “Салым түләүчеләр - оешмалар өчен салым түләү әлеге салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешен җир кишәрлеге кадастр бәясенең процент ставкасы күләмендә, узган хисап чорыннан соң килә торган айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча, тиешле салым ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла дип билгеләргә Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru) «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Абалач авыл җирлеге Советы рәисе Р.Н. Сиражетдинов